**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре турында» Указына үзгәрешләр кертү турында

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре турында» 2000 елның 6 июнендәге ПУ-394 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2000 елның 6 июлендәге ПУ-491 номерлы, 2000 елның 2 ноябрендәге ПУ-829 номерлы, 2002 елның 31 гыйнварындагы ПУ-65 номерлы, 2002 елның 15 ноябрендәге ПУ-992 номерлы, 2003 елның 1 апрелендәге ПУ-235 номерлы, 2003 елның 4 августындагы ПУ-563 номерлы, 2004 елның 10 мартындагы ПУ-163 номерлы, 2004 елның 21 июнендәге ПУ-461 номерлы, 2004 елның 14 сентябрендәге ПУ-604 номерлы, 2005 елның 28 маендагы ПУ-214 номерлы, 2005 елның 22 декабрендәге ПУ-513 номерлы, 2006 елның 18 февралендәге ПУ-64 номерлы, 2006 елның 4 апрелендәге ПУ-128 номерлы, 2006 елның 18 маендагы ПУ-179 номерлы, 2007 елның 3 декабрендәге ПУ-646 номерлы, 2007 елның 25 декабрендәге ПУ-698 номерлы, 2008 елның 17 декабрендәге ПУ-660 номерлы, 2009 елның 3 июнендәге ПУ-318 номерлы, 2010 елның 4 февралендәге ПУ-42 номерлы, 2010 елның 21 июлендәге ПУ-475 номерлы, 2010 елның 9 декабрендәге ПУ-798 номерлы, 2012 елның 23 июнендәге ПУ-496 номерлы, 2012 елның 27 сентябрендәге ПУ-786 номерлы, 2012 елның 29 декабрендәге ПУ-1139 номерлы, 2013 елның 4 ноябрендәге ПУ-1072 номерлы, 2014 елның 22 сентябрендәге ПУ-910 номерлы, 2015 елның 31 июлендәге ПУ-691 номерлы, 2016 елның 23 гыйнварындагы ПУ-24 номерлы, 2016 елның 15 ноябрендәге ПУ-1006 номерлы, 2017 елның 13 октябрендәге ПУ-909 номерлы, 2017 елның 7 ноябрендәге ПУ-986 номерлы, 2018 елның 16 маендагы ПУ-372 номерлы һәм 2018 елның 17 ноябрендәге ПУ-777 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советының Мәгълүмати куркынычсызлык буенча ведомствоара комиссиясе турында нигезләмәдә:

1 пунктта «Куркынычсызлык турында» Татарстан Республикасы Законы һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Комиссия эшчәнлегенең хокукый нигезен Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституцион законнар, федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм боерыклары, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм боерыклары, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы турында нигезләмә тәшкил итә.»;

4 пунктта:

алтынчы абзацта «республика дәүләт хакимияте органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «һәм өстәмәләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

унынчы абзацта «еллык юллама» сүзләрен «еллык юлламалар (хисаплар)» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта:

беренче абзацта «, үзгәртеп корыла» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «республика дәүләт хакимияте органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта:

икенче абзацта «республика һәм җирле дәүләт хакимияте органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «республика һәм җирле дәүләт хакимияте органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «республика һәм җирле дәүләт хакимияте органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктның икенче абзацында «республика дәүләт хакимияте органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктта «аппарат» сүзен «эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге» сүзләренә, «республика дәүләт хакимияте органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга;

б) Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советының Мәгълүмати куркынычсызлык буенча ведомствоара комиссиясе (алга таба – Комиссия) составында:

Комиссия составыннан Д.В. Вандюковны, Р.А. Шәйхетдиновны чыгарырга;

Комиссия составына кертергә:

Хәйруллин Айрат Ринат улын – Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрын, аны Комиссия рәисе итеп расларга;

Яковлев Альберт Валерьевичны – Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры урынбасарын, аны Комиссия рәисе урынбасары итеп расларга;

Комиссия әгъзасы В.В. Дьячковның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «АйСиЭл-КПО ВС» акционер җәмгыяте директорлар советы рәисе (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2019 ел, 14 декабрь
№ ПУ-747